МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ
И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ
ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.06.2016 № 337

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 4 июлендә теркәлде, № 3420

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
"Укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге
балигъ булмаган гражданнарны,
эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны,
урта һөнәри белемгә ия булып,
беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге
яшьтәге эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында
вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын
раслау турында" 30.11.2015 ел, № 880
боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында **боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18

дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.11.2015 ел, № 880 боерыгына кертелүче кушымта итеп бирелүче үзгәрешләрне расларга.

2. Бу боерыкның гамәлдә булуы 2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла, дип билгеләргә.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.06.2016 ел, № 337 боерыгы белән расландылар

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.11.2015 ел, № 880 боерыгына кертелүче үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.11.2015 ел, № 880 боерыгында (алга таба – Боерык) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Административ регламентның укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүгә дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерактагы эш урыннары аша гариза бирү өлешендәге пунктлары КФҮ һәм Татарстан Республикасының халык мәшгульлеге хезмәтләре дәүләт учреждениеләре

арасында килешү имзаланганнан соң көченә керә.”;

Укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Боерык белән расланган административ регламентында (алга таба – Административ регламент):

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1 (1 өл.), 3 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясендә халык мәшгульлеге турында” 19 апрель, 1991 ел, № 1032-1 Россия Федерациясе законы (Россия Федерациясенең Халык депутатлары съезды һәм Россия Федерациясе Югары Советы хәбәрләре, 1991, № 18, 566 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) [13];

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) [14];

“Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында” 27 июль, 2006 ел, № 149-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өл.), 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өлеш), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) [15];

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) [16];

"Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" 07.05.2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.) [17];

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Кулай эш эзләү максатларында гражданнарны теркәү, эшсез гражданнарны теркәү тәртибе һәм кулай эшне сайлауга таләпләр турында" 2012 елның 7 сентябрендәге № 891 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 38, 5103 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Персональ мәгълүматларны персональ мәгълүмат системаларында эшкәрткәндә, аларны саклауга таләпләрне раслау турында" 2012 елның 1 ноябрендәге № 1119 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 45, 6257 ст.);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 8 ноябрендәге "Халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәте алучыларның (физик затлар һәм эш бирүчеләрнең) регистрларын алып бару тәртибе турында (аларда мәгълүмат күрсәтүнең тәртибен, срокларын һәм формасын кертеп)" № 972н боерыгы (Российская газета, 2011, № 20);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 26 февралендәге "Халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәте алучының "личное дело"сы бланклары формасын раслау турында" № 125н боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 06.04.2015)[18];

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелүче: инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы тернәкләндерү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын һәм аларның формаларын төзү һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" 2015 елның 31 июлендәге № 528н боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 24.08.2015);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 29 июнендәге "Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль

түләүләр башкару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" № 10н боерыгы белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләр башкару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (Российская газета, 2012, № 213, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)[19];

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының "Укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрен тәмамлаганнар исәбендә булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында" 2013 елның 12 февралендәге № 58н боерыгы белән расланган Укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрен тәмамлаганнар исәбендә булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандарты (Российская газета, 2013, № 107, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)[20];

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре" 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – № 880 Тәртип) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)[21];

"2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы халкының мәшгульлегенә ярдәм итү" Дәүләт программасын раслау турында" 09.08.2013, № 553 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2013, № 62, 1946 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Гражданнарга кулай эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышу дәүләт хезмәтен күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 17 июнендәге "Гражданнарга кулай эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышу дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" № 419 боерыгы белән расланган административ регламенты ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2015, № 78, 2718 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) [22].";

14 – 18 сноскаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"[14]Алга таба – 24.11.1995 ел, № 181-ФЗ Федераль закон.

[15]Алга таба – 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон.

[16]Алга таба – 06.04.2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон.

[17]Алга таба – № 601 Указ.

[18]Алга таба – 26.02.2015 ел, № 125н боерык.";

21 сносканы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"[21]Алга таба – № 880 Тәртип.";

таблицаның 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | 1. Укудан буш вакытларында 14 тән 18 яшькә кадәрге яшьтәге балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге яшьтәге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру. | Халык мәшгульлеге турындагы законның 7.1-1 ст. 1 п. 8 п-часы.”; |

таблицаның 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып; туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне | ХМҮгә беренче тапкыр мөрәҗәгать итүче гариза бирүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтүнең рөхсәт ителгән максималь вакыты 20 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Гариза бирүчеләр кабат мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтүнең рөхсәт ителгән максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>ХМҮгә мөрәҗәгать итү көнен һәм вакытын гражданнар белән килештерү, гариза теркәлгән көннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча, телефон элемтәсе яки, Интернет челтәрен дә кертеп, электрон элемтә чараларыннан файдаланып, почта элемтәсе белән | № 58н Федераль стандартның 24 п.;<br>№ 58н Федераль стандартның 25 п.;<br>№ 58н Федераль стандартның 8 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| туктатып тору срогы | башкарыла.<br>Гражданинның мөрәҗәгать итү көнен һәм вакытын алдан килештергән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Гражданнар КФҮгә, ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны КФҮ һәм ХМҮ арасында хезмәттәшлек итү турындагы килешү белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин гариза теркәлгән көннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча, ХМҮгә тапшыру тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору ихтималы Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылмаган. | № 58н Федераль стандартның 9 п..”; |

таблицаның 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче | Дәүләт хезмәте күрсәтелү өчен гариза бирүчегә кирәкле документлар булып торалар:<br>- дәүләт хезмәте күрсәтү турында 26.02.2015 ел, № 125н боерыкның 27 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча гариза яки түләнелүче җәмәгать эшләрен башкаруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында ХМҮ белгече тарафыннан бирелгән тәкъдим, һәм | № 58н Федераль стандартның 5 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | гариза бирүченең ХМҮ белгече тәкъдименә 26.02.2015 ел, № 125н боерыкның 28 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча ризалыгы;<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен таныклаучы документ (чит ил гражданнары өчен);<br>- гражданлыксыз затның шәхесен таныклаучы документ (гражданлыксыз затлар өчен);<br>- инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең билгеләнгән тәртиптә бирелүче һәм хезмәтнең киңәш ителүче рәвеше һәм шартлары турында бәяләмәне үз эченә алучы индивидуаль программасы (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен).<br>Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче ХМҮгә шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы ХМҮнең рәсми сайтына, Татарстан Республикасы порталына | № 58н Федераль стандартның 12 п.;<br>24.11.1995 ел, № 181-ФЗ Федераль закон;<br>№ 58н Федераль стандартның 6 п..”; |

| | | |
|---|---|---|
| | урнаштырылган.<br>Гариза бирүчеләргә гариза бирү ысулын сайлап алу мөмкинлеге тәэмин ителә: ХМҮгә шәхсән мөрәҗәгать итеп, почта аша (электрон почтаны да кертеп), факсимиль элемтә ярдәмендә яки электрон документ рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталдан яки Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып яисә гаризаны КФҮ аша, ерактагы эш урыны аша тапшырып. | |

таблицаның 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| "2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документны тапшырмау.<br>2. Документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу."; | |

таблицаның 2.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| "2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр күздә тотылмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булып, түбәндәгеләрнең булмавы тора: | № 58н Федераль стандартның 12 п.."; |

| | | |
|---|---|---|
| тулы исемлеге | - Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алыштыручы документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен таныклаучы документ (чит ил гражданнары өчен);<br>- гражданлыксыз затның шәхесен таныклаучы документ (гражданлыксыз затлар өчен);<br>- инвалидны тернәкләндерүнең яисә инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең билгеләнгән тәртиптә бирелүче индивидуаль программасы (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен)[24]. | |

таблицаның 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| "2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | № 58н Федераль стандартның 11 п..."; |

таблицаның 2.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | ХМҮгә беренче тапкыр мөрәҗәгать итүче гариза бирүчеләр шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте чират буенча күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүченең чиратта көтү вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Көнен һәм вакытын алдан килештергән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне көтү вакыты 5 минуттан артырга тиеш түгел. | № 58н Федераль стандартның 7 п.;<br>№ 601 Указ;<br>№ 58н Федераль стандартның 8 п..”; |

таблицаның 2.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен (шул исәптән электрон рәвештәге) теркәү срогы | Гариза кергән көнне.<br>Гаризаны теркәү дигәнне, ХМҮнең гариза бирүчеләр күрсәткән документларда булган мәгълүматларны, исәпкә алу язуының теркәү номерын биреп, Халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучыларның – физик затларның электрон регистрына кертүе дип аңларга кирәк.<br>Гариза бирүченең рәсми мөрәҗәгате буенча, гаризаның гаризаны кабул итү көне һәм исәпкә алу язуының теркәү номеры турында мәгълүматы булган күчермәсе бирелергә мөмкин. | Халык мәшгульлеге турындагы законның 16.1 ст. 2 п..”; |

таблицаның 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| "2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына тәңгәл рәвештә, әлеге объектларның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга һәм | Дәүләт хезмәте күрсәтү аерым махсус җиһазландырылган, инвалидларның, кәнәфи-арбалардан файдаланучы инвалидларны да кертеп, тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итүче бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле офис җиһазы, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыныннан инвалидларның тоткарлыксыз файдалана алуы, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керүе һәм алардан чыгуы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү урынына бару максатыннан, объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә керү һәм аннан чыгу урыннары автоном өзлексез ток чыганагы булган тиешле күрсәткеч язулар белән җиһазландырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарында җәмәгатьчелек файдалана ала торган | № 58н Федераль стандартның 10 п..”; |

| | | |
|---|---|---|
| рәсмиләштерүгә карата таләпләр | урыннар (бәдрәфләр) һәм килүчеләрнең өс киемнәрен саклау урыннары булдыру күздә тотыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыннары тавышлы мәгълүмат һәм электрон хәбәр итү системалары белән җиһазландырыла.<br>ХМҮ белгеченең эш урыны стенага эленгән мәгълүмат тактасы яки өстәл өстенә куелган, фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән табличка белән җиһазландырыла.<br>ХМҮ белгечләре күкрәккә тагыла торган, фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән шәхси карточкалар (бейджлар) белән тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, шулай ук Интернет-ресурсларда (Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы порталында) урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында текстлы һәм мультимедиаль мәгълүматны рәсмиләштерү | |

| | | |
|---|---|---|
| | гражданнарның бу мәгълүматны күреп һәм ишетеп, уңайлы рәвештә кабул итүенә туры килергә тиеш. | |

таблицаның 2.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен КФҮдә, ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:<br>1. Шәхси яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү рәвешендә гариза бирүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турындагы, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар рәсмиләштерү үрнәкләре турындагы мәгълүматны алу мөмкинлеге (шәхсән кабул итү вакытында, телефон элемтәсе чараларын, электрон почтаны файдаланып, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару, мәгълүматлы материаллар (брошюралар, памяткалар, буклетлар һ.б.) нәшер итү, мәгълүматны Татарстан Республикасы порталына урнаштыру ярдәмендә).<br>2. Гариза бирүченең гаризалар формаларыннан һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле башка документлардан файдалана алу мөмкинлеген, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә | № 880 Тәртипнең 2.4 п.;<br>№ 601 Указның 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| файдаланып | тутыру мөмкинлеген дә тәэмин итү.<br>3. Инвалидларга аларның хезмәт күрсәтүләрне башка затлар белән бертигез алуына комачаулаучы киртәләрне узуда ярдәм күрсәтү;<br>4. Гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтү вакыты саклану.<br>5. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән телефон элемтәсен, электрон почтаны файдаланып, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы порталы, КФҮ, ерактагы эш урыны аша, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтыннан.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, ХМҮ тарафыннан Россия Федерациясенең халык мәшгульлеге турындагы законы таләпләре, бу Регламентның нигезләмәләре үтәлү.<br>2. Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары үтәлү.<br>3. Бу Регламент белән билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге үтәлү.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуларның нигезлелеге. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы.<br>Гариза бирүченең ХМҮ белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә турыдан-туры – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>документларны почта аша, шул исәптән электрон документ рәвешендә җибәргәндә – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүченең ХМҮ белгече белән бер тапкыр аралашуының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте КФҮ, ерактагы эш урыны аша күрсәтелми.<br>Гариза бирүче КФҮгә, ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны ХМҮгә тапшыру тәэмин ителә, ләкин гариза теркәлгән көннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, ХМҮ һәм КФҮ хезмәттәшлегенең тәртибе ХМҮ һәм КФҮ арасында хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән | № 58н Федераль стандартның 9 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмəттəшлегенең тəртибе КФҮ эше регламенты белəн җайга салына.<br>Дəүлəт хезмəте күрсəтү барышында гариза бирүчелəргə эш бирүче белəн телефон элемтəсе яки Интернет челтəреннəн файдаланып, видеоэлемтə ярдəмендə əңгəмəлəр үткəрү мөмкинлеге тəэмин ителə.<br>Дəүлəт хезмəте күрсəтүнең барышы турындагы мəгълүматны гариза бирүче http://mtsz@tatarstan.ru сайтыннан, Дəүлəт хезмəтлəре һəм муниципаль хезмəтлəрнең бердəм порталыннан алырга мөмкин. | № 58н Федераль стандартның 28 п..”; |

таблицаның 2.16 пунктын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

| | | |
|---|---|---|
| “2.16. Электрон формада дəүлəт хезмəте күрсəтү үзенчəлеклəре | Дəүлəт хезмəте, дəүлəт хезмəте күрсəтүгə гариза бирүдəн гайре, электрон рəвештə күрсəтелми.<br>Халык мəшгульлеге өлкəсендə дəүлəт хезмəтлəре алучылар – физик затлар – регистрында алар турында мəгълүматлар булган граждannarга, телефон элемтəсе яки электрон элемтə | № 58н Федераль стандартның 27 п..”; |

| | | |
|---|---|---|
| | чараларыннан файдаланып, вакытлыча җәмәгать эшләрендә катнашу өчен эшкә урнашуга буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) булу-булмау турында, өч көн эчендә ХМҮгә килү тәкъдиме белән, белешмәләр керү хакындагы мәгълүматны алу мөмкинлеге тәэмин ителә. | |

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасындагы беренче абзацта “дәүләт хезмәте күрсәтү турында яисә” сүзләреннән соң “дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне бирү һәм” сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктның 3.3.2 пунктчасында “бер эш көне эчендә” сүзләрен “көнне” сүзенә алмаштырырга;

5.1 пунктның икенче абзацында “, җитәкче кабул иткән” сүзләрен “җитәкченең” сүзенә алмаштырырга;

5.1 пунктның өченче абзацында “, министр урынбасары (министр) кабул иткән” сүзләрен “министр урынбасарының (министрның)” сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктның икенче абзацында “, ерактагы эш урыны” сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Халык мәшгульлеге үзәге атамасы | Телефоны | Урнашкан урыны адресы, электрон адресы |
|---|---|---|
| “Менделеев районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУның Әгерҗе районындагы филиалы | (85551) 2-31-73 | 422230, Әгерҗе ш., К.Маркс ур., 11а й. Centr.Agryzskiy@tatar.ru |

| Халык мәшгульлеге үзәге атамасы | Телефоны | Урнашкан урыны адресы, электрон адресы |
|---|---|---|
| “Азнакай шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85592) 7-57-90 | 423330, Азнакай ш., Төзүчеләр ур., 10 й. Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| “Аксубай районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84344) 2-73-94 | 423060, Аксубай ш.т.б., Романов ур., 6 й Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| “Актаныш районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85552) 3-09-83 | 423740, Актаныш ав., Ленин пр., 8 й. Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| “Алексеевск районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84341) 2-54-00 | 422900, Алексеевск э.б., Ленин ур., 87 й. Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| “Әлки районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84346) 2-15-89 | 422870, Базарлы Матак ав., Совет ур., 8 й. Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| “Әлмәт шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (8553) 32-34-99 | 423452, Әлмәт ш., Герцен ур., 86а й. Czn.Almet@tatar.ru |
| “Апас районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84376) 2-12-15 | 422350, Апас ав., Шоссе ур., 5 й Czn.Apastovo@tatar.ru |
| “Арча районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84366) 3-17-33 | 422000, Арча ш.т.б., Банк ур., 6в й. Centr.Arskiy@tatar.ru |
| “Әтнә районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84369) 2-16-51 | 422750, Олы Әтнә ав., Совет ур., 63 й. Czn.Atnya@tatar.ru |
| “Баулы шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85569) 5-62-29 | 423930, Баулы ш., Энгельс ур., 56 й. Czn.Bavly@tatar.ru |
| “Балтач районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84368) 2-44-19 | 422250, Балтач ш.т.б., Совет ур., 16 й. Czn.Baltasi@tatar.ru |
| “Бөгелмә шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85594) 4-17-60 | 423230, Бөгелмә ш., Октябрь ур., 15 й. Czn.Bugulma@tatar.ru |
| “Буа шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84374) 3-13-73 | 422430, Буа ш., Р.Люксембург ур., 157/1 й. Czn.Buinsk@tatar.ru |
| “Югары Ослан районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84379) 2-18-99 | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 1 й. Czn.V-uslon@tatar.ru |
| “Биектау районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84365) 3-16-17 | 422700, Биектау ав., Үзәк ур., 7 й. CZN.VGora@tatar.ru |
| “Чүпрәле районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84375) 2-25-87 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Мәктәп ур., 16 й. Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| “Алабуга шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85557) 7-58-58 | 423600, Алабуга ш., Спас ур., 5 й. Czn.Elabugi@tatar.ru |

| Халык мәшгульлеге үзәге атамасы | Телефоны | Урнашкан урыны адресы, электрон адресы |
|---|---|---|
| “Зәй шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85558) 7-15-43 | 423520, Зәй ш., Нефтьчеләр пр., 39 й. Czn.Zainsk@tatar.ru |
| “Зеленодольск шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84371) 5-64-90 | 422550, Зеленодольск ш., Татарстан ур., 1й. Czn.Zdol@tatar.ru |
| “Кайбыч районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84370) 2-12-60 | 422330, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й. Czn.Kaibicy@tatar.ru |
| “Тәтеш районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУның Кама Тамагы районындагы филиалы | (84377) 2-14-67 | 422820, Кама Тамагы ш.т.б., К. Маркс ур., 2 й. Filial.K-uste@tatar.ru |
| “Кукмара районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84364) 2-67-54 | 422110, Кукмара ш.т.б., Ворошилов ур., 44 й. Czn.Kukmor@tatar.ru |
| “Лаеш районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84378) 2-48-12 | 422610, Лаеш ш.т.б., Беренче Май ур., 16 й. Laish.Czn@tatar.ru |
| “Лениногорск шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85595) 5-59-70 | 423250, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 й. Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| “Мамадыш районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85563) 3-35-57 | 422190, Мамадыш ш., Карл Маркс ур., 14 й. Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| “Менделеев районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85549) 2-23-57 | 423650, Менделеев ш., Фомин ур., 19 й. Czn.Men@tatar.ru |
| “Минзәлә районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85555) 3-23-80 | 423700, Минзәлә ш., Ленина ур., 78 й. Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| “Мөслим районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85556) 2-55-80 | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й. Czn.Muslymovo@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (8552) 52-42-68 | 423831, Чаллы ш., Сөембикә пр., 47 й. Chelny.CZN@tatar.ru |
| “Түбән Кама шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (8555) 42-40-79 | 423570, Түбән Кама, Бызов ур., 20а й. Czn.Nk@tatar.ru |
| “Түбән Кама шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУның Кама Аланы бүлеге | (8555) 33-98-61 | 423564, Түбән Кама районы, Кама Аланы э.б., 2/01 й. Czn.Nk@tatar.ru |
| “Яңа Чишмә районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84348) 2-30-42 | 423190, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 й. Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| “Нурлат шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84345) 2-46-30 | 423040, Нурлат ш., Хәмәдиев Р.С.ур., 19 й. Czn.Nurlat@tatar.ru |

| Халык мәшгульлеге үзәге атамасы | Телефоны | Урнашкан урыны адресы, электрон адресы |
|---|---|---|
| “Питрәч районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84367) 3-04-84 | 422770, Питрәч ав., Совет ур., 34 й. CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| “Балык Бистәсе районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84361) 2-21-81 | 422650, Балык Бистәсе ш.т.б., Ленин ур., 48 й. Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| “Саба районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84362) 2-44-11 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.б., Тукай ур., 87 й. SZN.Saby@tatar.ru |
| “Сарман районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85559) 2-42-62 | 423350, Сарман ав., Ленин ур., 26 й. Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| “Спас районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84347) 3-07-72 | 422820, Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 21 й. Czn.Bolgar@tatar.ru |
| “Тәтеш районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84373) 2-63-29 | 422370, Тәтеш ш., Ирек Мәйданы ур., 45 й Czn.Tetyushi@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУның Тукай районындагы филиалы | (8552) 52-96-97 | 423831, Чаллы ш., Сөембикә пр., 47 й. Czn.Tukaev@tatar.ru |
| “Теләче районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84360) 2-13-51 | 422080, Теләче ав., Ленин ур., 73 й. Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| “Чирмешән районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84396) 2-54-59 | 423100, Чирмешән ав., Титов ур., 5 й. Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| “Чистай шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (84342) 5-13-34 | 422980, Чистай ш., К.Маркс ур., 35 й. Czn.chist@tatar.ru |
| “Ютазы районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (85593) 2-98-00 | 423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур, 38 й. Czn.Yutazy@tatar.ru |
| “Казан шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 562-48-33 | 420034, Казан ш., Декабристлар ур., 81а й. Czn.g_Kazan@tatar.ru |
| “Казан шәһәре Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУның Совет районындагы филиалы | (843) 273-85-03 | 420029, Казан ш., Журналистлар ур., 13а й. CZN/Sovetskiy@tatar.ru |
| “Авиатөзелеш районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 537-86-00 | 420085, Казан ш., 1 нче Муром ур., 33а й. Czn.Avia@tatar.ru |
| “Вахитов районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 277-51-59 | 420059, Казан ш., Павлюхин ур., 102 й. Czn.Vah@tatar.ru |
| “Киров районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 554-77-36 | 420032, Казан ш., Слобода ур., 23 й. czn.kirovskiy@tatar.ru |

| Халык мәшгульлеге үзәге атамасы | Телефоны | Урнашкан урыны адресы, электрон адресы |
|---|---|---|
| “Мәскәү районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 534-58-72 | 420039, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. czn.moskovski@tatar.ru |
| “Яңа Савин районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 560-88-98 | 420044, Казан ш., Ибраһимов ур., 41 й. Czn.Novosavin@tatar.ru |
| “Идел буе районы Халык мәшгульлеге үзәге” ДКУ | (843) 224-86-83 | 420101, Казан ш., Бертуган Касыймовлар ур., 22/7 й. CZN.Privol@tatar.ru |